**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

28 июнь 2016 ел № 17/3

Иҗтимагый фикер алышуларны
(тыңлауларны) раслау турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә планлаштырыла торган «Түбән Кама» милли паркының федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигать территориясе чикләрендә, «Сосновый бор» ДНТ торак йортларын газлаштыру системасын техник яктан яңадан җиһазландыру» дәүләти экологик экспертиза үткәрергә тиешле эшчәнлек турында фикер алышуларның (тыңлауларның) нәтиҗәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегеуставына таянып, муниципаль берәмлек Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә планлаштырыла торган «Түбән Кама» милли паркының федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигать территориясе чикләрендә, «Сосновый бор» ДНТ торак йортларын газлаштыру системасын техник яктан яңадан җиһазландыру» дәүләти экологик экспертиза үткәрергә тиешле эшчәнлек турында фикер алышуларны (тыңлауларны) расларга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Г.Н. Харитонов